Республика Татарстан
Глава Тураевского сельского поселения
Менделеевского муниципального района

423647, Менделеевский район, с.Тураево,
ул. Центральная, д 11а

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге Башлыгы

423673, Менделеевск районы, Турай авылы,
Үзәк урамы, 11а

тел./факс 8/85549/2-73-31, E-mail: Tur.Men@tatar.ru, http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/turaevskoe-selskoe-poselenie.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

8 ноябрь 2019 ел. № 1

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлегендә
гражданнар җыенын гамәлгә кертү
һәм гражданнарның үзара салым акчаларын
куллану мәсьәләсе буенча

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә **КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 23 ноябрендә Турай авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. 2019 елның 23 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Турай авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча икенче этапны билгеләргә.
3. 2019 елның 23 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Турай авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча өченче этапны билгеләргә.
4. 2019 елның 23 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Турай авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча дүртенче этапны билгеләргә.

Турай авылы, Үзәк урамы , 11 йорт адресы буенча урнашкан Турай авылы мәдәният йорты җыеннарның барлык этапларын үткәрү урыны итеп билгеләргә.

Турай авылында яшәүчеләрнең исемлеген җыеннар этапларына территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә җитештерергә:

Беренче этап: 1-нче йорттан 4-нче номерлы Кама урамы, Яңа урамы 1-нче йорттан 3-нче номерлы йортка кадәр, Яшьләр урамы, 8-нче йорттан 10-нчы

номерлы йортка кадәр, Окольная урамы-1-нче йорттан 37-нче номерлы йортка кадәр.

Икенче этап: 1нче йорттан 37нче йортка кадәр Овражная урамы, 1нче йорттан 33нче йортка кадәр Совет урамы.

Өченче этап: 1нче йорттан 44нче йортка кадәр Үзәк урам, 1нче йорттан 33нче йортка кадәр Кырый урамы.

Дүртенче этап: 1нче йорттан 18нче йортка кадәр Тынычлык урамы, Мәктәп урамы 1нче йорттан 12 нчесенә кадәр.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2020 елда Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- мәйданчык урнаштыру һәм спорт инвентаре сатып алу ;

- насос сатып алу

«ӘЙЕ» «ЮК»

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Турай авыл җирлеге» бүлегендә кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Турай авыл җирлеге Башлыгы Рахимова А.М.